Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №III- 8**

Балык Бистәсе штп. 2020 елның 16 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2014 елның 12 ноябрендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы нигезләмәне раслау хакында” XLI-8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында” 2020 елның 20 июлендәге 241-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2014 елның 12 ноябрендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы нигезләмәне раслау хакында” XLI-8 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 01.04.2019 ел XLI-11, 26.06.2019 ел XLIII-5 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 3.2.9 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 14 абзацны өстәргә:

“- полициянең участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына күрсәтелгән вазыйфаны хезмәткәр биләгән чорга торак урыны бирү”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы вазыйфаларын башкаручы Ф.Г. Әхмәтҗанова